ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Заводская, д.5, с. Нижний Услон,
422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан,
422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

05.11.2025 с. Нижний Услон № 1

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Воробьевка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 18 ноябренә Югары Ослан районының Түбән Ослан авыл җирлеге Воробьевка авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Воробьевка авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 42 943 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- Воробьевка авылында су белән тәэмин итү һәм су түгү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (урамнарны су белән тәэмин итү системасына экспертиза үткәреп, су белән тәэмин итү системасын проектлау)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Воробьевка авылы, Пионер урамы, кибет бинасы янында 11.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Түбән Ослан авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев